Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
## УНИВЕРСИТЕТ

12+

№ 36 (129)

18 декабрь 2014 ел



# Россиянең иң гүзәл ТАТАР КЫЗЫ!

**Күптән түгел Мәскәүнең «КВН» планетасы концерт залында «Татар кызы – 2014» Бөтенроссия матурлык конкурсы финалы узды. Ул татар халкы өчен иң зур күләмле чара булып исәпләнә. Аның төп максаты – милли, әхлак һәм гаилә кыйммәтләрен пропагандалау, татар телен һәм мәдәниятен популярлаштыру, шулай ук фестивальдә җиңеп, тажга лаек булган гүзәл татар кызын Россиянең бөек халкының заманча, уңышлы, чибәр һәм югары интеллектка ия вәкиле буларак күрсәтү. Барлык сынауларны үтеп, уку йортыбызның Идарә, икътисад һәм финанслар институтында инженер-эколог һөнәрен үзләштерүче 20 яшьлек Алинә Гыйззәтуллина җиңүче булды.**

## • Вакыйгалар эзеннән

11 **ДЕКАБРЬ** көнне Л.Н.Толстой ис. фәнни-мәгариф халыкара яшьләр фестивале кысаларында Актлар залында **«ВИВАТ, УНИВЕРСИТЕТ»** дип аталган **ӘДӘБИ КОНКУРСНЫҢ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕН БҮЛӘКЛӘҮ ТАНТАНАСЫ УЗДЫ**. Әлеге бәйге университетның Хатын-кызлар лигасы тарафыннан оештырылды һәм уку йортының 210 еллыгына багышланды. Конкурска төрле жанрдагы иҗади эшләр кабул ителде. Әмма аларның Казан университеты белән бәйле булуы шарт иде. Әдәби бәйгенең җиңүчеләре дип, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты аспиранты Булат Ханов, Фундаменталь медицина һәм биология институты студенты Артур Сабиров һәм университетның чыгарылыш студенты, ТР Фәннәр Академиясе матбугат сәркатибе Маргарита Небольсина табылды.

• • • •

12 **ДЕКАБРЬДӘ** «XXI гасыр материаллары һәм технологияләре» Бөтенроссия мәктәп-конференциясенең **ИҢ ЯХШЫ ДОКЛАД АВТОРЛАРЫН ТӘБРИКЛӘДЕЛӘР**. Катнашучылар биомедицина, перспектив материаллар һәм нефть эшкәртү, нефть эшкәртү һәм нефтехимия юнәлешләрендә чыгыш ясадылар. Барлыгы 350 доклад тыңланды. Шулар арасыннан 20се иң яхшылары дип табылды. Аларның авторларын КФУның фәнни эшчәнлек буенча проректоры Д.Нургалиев һәм конференциянең иганәче компания вәкилләре тәбрикләде.

• • • •

16 **ДЕКАБРЬДӘ** КФУ базасында «**UNIVERSITAS**» фәлсәфә-политология **ХАЛЫКАРА ЯШЬЛӘР ФОРУМЫ ҮЗ ЭШЕН БАШЛАП ҖИБӘРДЕ**. Аның эшчәнлегендә Россия, СНГ илләре, Греция, Кытай, Чехия, АКШтан килгән 100дән артык студент катнаша. Форум кысаларында секция утырышлары уздырылачак, Казан университеты һәм Мәскәү югары уку йортлары профессорлары ачык лекцияләр үткәрәчәк. Шулай ук чит ил университетлары белән дә телекүпер оештырылачак, дип көтелә. Моннан тыш, ТР Дәүләт Советы депутатлары катнашында «Парламент дебатлары» уены уздырылачак һәм Казан мэры И.Метшин «Шәһәр башлыгының уңыш серләре» дип исемләнгән мастер-класс үткәрәчәк.

• • • •

Күптән түгел ТР Инвестицион-венчур фонды һәм ТР Фәннәр академиясе тарафыннан менә инде 10нчы мәртәбә уздырыла торган **«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӨЧЕН ИҢ ЯХШЫ 50 ИННОВАЦИОН ИДЕЯ»** дип исемләнгән **КОНКУРСКА НӘТИҖӘЛӘР ЯСАЛДЫ**. Җиңүчеләрне тантаналы төстә ТР Президенты Р.Миңнеханов һәм ТР премьер-министры И.Халиков бүләкләде. Быел җиңүче-инноваторлар арасында 23 КФУ вәкиле: студентлар да, аспирантлар да, профессорлар да бар.

• • • •

**КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ ТАРИХЫН КЕМ ЯХШЫРАК БЕЛӘ?** Бу сорауга җавапны ноябрь буе эзләделәр. Чөнки нәкъ менә узган ай дәвамында студентлар университетның үткәненә багышланган викториналарда көч сынашты. Әлеге конкурс, гадәттәгечә, Казан университеты тарихы музеенда узды. Бәйге кысаларында студентлар уку йорты тарихында якты эз калдырган шәхесләр, аларның тормышы, фәнни эшчәнлеге, университетта ясалган ачышларга багышланган сорауларга җавап бирде. Нәтиҗәдә командалар беренчелегендә дә, шәхси беренчелектә дә урыннар бирелде. Барлык җиңүчеләргә кубоклар, истәлекле бүләкләр һәм Россиянең тарихи урыннары буенча сәяхәт итү мөмкинлеге тәгаенләнде.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

• Галимнәребез

**Инде ярты гасырга якын төрки-татар, фин-угыр галимнәр берләшмәсендә филология фәннәре докторы, профессор, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе Леонид Шәйсолтан улы Арсланов исеме билгеле. Декабрь аенда туган көнен билгеләп узучы әлеге шәхес үзенең бар тормышын фәнни эзләнүләр, мәдәниятккә һәм кешеләргә хезмәт итүгә багышлаган.**

# Гадилектә аның бөеклеге

**Лилия САЛИМЯНОВА, Алинә БӘДЕРТДИНОВА,**
Алабуга институты

Леонид Шәйсолтан улы Татарстан Республикасы Актаныш районы Мари Ямалы авылында гади игенче гаиләсендә туган. Аның авылдашлары икe телне дә бик яхшы белгәннәр (татар һәм мари телен). Үз авылларында мәктәп булмаганлыктан, аларга күрше Татар Ямалы авылына барып, татар мәктәбендә укырга туры килә. 1947 елда 7 еллык мәктәпне тәмамлап, ул Минзәлә педагогия училищесына укырга китә. Әлеге кечкенә генә тарихи шәһәрчек мәңгегә аның хәтерендә кала.

Училищеда укуын яхшы тәмамлап, ул үз районындагы Яңа Богады авылына 7 еллык мәктәпкә башлангыч сыйныф укытучысы итеп билгеләнә. Монда укыткан вакытта Леонид Шәйсолтан улы һөнәрен дөрес сайлаганын аңлый. Тик 1952 елның гыйнвар аенда аны армия сафларына алалар. Аннан кайткач, Леонид абый үз авылында эшли һәм югары уку йортына керергә әзерләнә. Филология бүлеген сайлый, аның укытучы булу теләге көннән-көн арта.

Алабуга институтының татар һәм рус теле бүлегендә укыган вакытта, Леонид Шәйсолтан улы үзенең зур мөмкинлекләрен күрсәтә. 1960 елда институтны тәмамлагач, аны Омск өлкәсенә эшкә җибәрергә телиләр. Ләкин фән белән мавыккан бу тырыш студентны уку йорты җитәкчеләре татар теле һәм әдәбияты кафедрасында ассистент итеп эшкә калдырырга карар кыла.



Икенче елында инде яшь укытучы Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтына аспирантурага керә. 1964 нче елда Л.Ш.Арсланов «ТАССР һәм ЧАССРның уңъяк яр өлкәләрендә татар сөйләше» дип исемләнгән диссертация эшен тәгъләп. 1966 елда, Алабуга педагогика институты студентлары арасыннан беренче булып, үзенең эшен Казанда яклый һәм филология фәннәре кандидаты исеменә лаек була.

Аспирантурада укыган елларында Леонид Шәйсолтан улы күп кенә күренекле галимнәр белән таныша. Алар арасында профессор Л.Җәләй, Л.Мәхмүтова, Н.Борханова, В.Хангилдин да була. Арсланов үзе дә филология өлкәсендә күп көч куя: ул чакта билгеле булган төрки әдәбиятның төп өлешен өйрәнә, Казан һәм Ульяновск шәһәрләрендәге архивларда эшли, диалектология фәне буенча тикшеренүләр уздыра.

*Күренекле профессор бөтен җаны-тәне белән филология фәненә гашыйк. Һәм бу фәнсөярлек – аның өчен дә, татар дөньясы өчен дә бик зур бәхет, әлбәттә. Бүгенге көндә тюркология һәм фин-угыр дөньясында аңа тиң, аның кеби үзен аямыйча эшли торган галим бар микән?!*

*Мансур Сафин*

Алабуга педагогика институтының яхшы студентын күтә. Һәм Леонид абый хәзерге көнгәчә үзенең уку йортына тугры кала: анда өлкән укытучы, доцент була, докторлык диссертациясен яклаганнан соң, профессор исемен ала. Күп еллар татар филологиясе кафедрасын җитәкли. Аның исеме бөтендөнья фән өлкәсендә билгеле. Россия һәм чит илләрнең күп кенә тел белгечләре Алабуга шәһәрен нәкъ менә Леонид Шәйсолтан улы исеме, аның басмалары, фәнни конференцияләрдәге чыгышлары аркылы беләләр. Ул тел белеме фәне үсеше өчен күп көч куя.

Галим буларак, ул һәрчак, китаплар уку белән шөгыльләнүгә караганда, төрле телдә һәм диалектларда аралашучы кешеләр белән эшләүгә тартыла. Татар һәм төрки телләрнең диалектологик атласын төзүдә дә аның роле бик зур. 1968-1980 нче елларда, материал туплау өчен, ул һәр елны экспедицияләр оештыра: җәяүләп Татарстанның күп кенә районнарын, Волгоград, Әстерхан өлкәләрен, Ставрополь төбәген һәм Калмыкияне йөреп чыга. Леонид Шәйсолтан улының күп масштаблы тикшеренүләренең нәтиҗәсе буларак, 1980 елда язылып, 1982 елда Алма-Ата шәһәрендә яклаган «Утрау телләрнең һәм диалектларның оешуы һәм үсеше...» дип исемләнгән докторлык диссертациясе санала. Л.Ш.Арсланов Алабуга педагогика институтының студентлары арасында беренче фән докторы булырак таныла.

Шул ук елларда аның, бүгенге көндә дә төрки һәм татар теле өлкәләрендә әһәмияткә ия булган күп кенә язмалары басыла. Леонид Шәйсолтан улының бик күп эшләрендә төрки-татар сүзләрәнә булган тирән ихтирамлы карашы чагыла. Аның фәнни кызыксынулары моның белән генә чикләнми. Арсланов өчен бик кызыклы булган бер өлкә – ул фин-угыр топонимиясе. Ул, беренчеләрдән булып, татар укучыларын ногай фольклоры һәм прозасы үрнәкләре белән таныштыра.

Күренекле галимнең фәнни басмалары күптән инде ике йөздән арткан, алар арасында унысы – монографик тикшеренүләр.

Ветеранның күпьеллык фәнни һәм педагогик эш нәтиҗәләре сокландыргыч. Профессор Арслановның беркайчан да җәмәгать эшләреннән читтә калмавы һәркемгә мәгълүм: филология факультетының партоешма секретаре, институтның партбюро әгъзасы. Леонид Шәйсолтан улының фәнни-гамәли ярдәме тимәгән укытучыларны атау мөмкин түгелдер.

Төрле шәһәрләрнең уку йортларында профессор Арслановны беләләр. Казан, Алма-Ата, Ижау, Йошкар-Ола, Саранск һәм Тобольск... Һәркайда да ул тыйнак, тик шул ук вакытта яшәү көче белән тулы, тырышлыкта һәм укуда гына тормышның мәгънәсе бар икәнлеген аңлаучы кеше. Шуна күрә дә бу шәхес хакында сөйләү дә, язу да бик җиңел, чөнки бернәрсәне дә уйлап чыгарырга кирәкми, аның сокландыргыч тормышы һәм эшләре – үзе бөек сүз ул!

Бүген дә Леонид Шәйсолтан улы Арсланов укытучылар сафында, ул әле дә уку йортының төрле эшчәнлекләрендә катнаша. Укытучылар һәм студентлар өчен аның туган ягына багышланган күпьеллык тугры хезмәте бик мөһим. Аның фәнни тикшеренү эшләре, яңа ачышлары бүгенге көндә дә зур роль уйный.

Озын сүзнең кыскасы: ул – һәр яктан килгән шәхес. Леонид абый – безнең зур горурлыгыбыз! Гел шулай хәрәкәттә булып, озак еллар яшәргә насыйп булсын.

• Без кунакта

**КФУның Психология һәм мәгариф институты белән И.Алтынсарина исемендәге Мәгариф милли академиясе арасында хезмәттәшлек меморандумын гамәлгә ашыру кысаларында уку йортыбыз профессоры Г.Җ.Фәхретдинова һәм доценты Е.М.Шувалова «Мәгарифтә инновацияләр: эзләү һәм чишү юллары» Халыкара фәнни-гамәли конференциядә катнашты.**

# КФУның педагогик моделе нинди?

**Дания ФАТЫЙХОВА**



Чара Казахстанның Астана шәһәрендә уздырылды. Конференциядә Россия, Казахстан, Эстония, АКШ, Бөекбритания һ.б. илләрдән килгән галимнәр, тикшеренүчеләр, укытучылар, уку йортлары җитәкчеләре, сәясәтчеләр фәнни-педагогик мәгарифтә соңгы инновацион тикшеренүләр һәм практик тәҗрибә белән уртаклашу мөмкинлегенә ия булдылар. Бирегә шулай ук Казахстандагы педагогик мәгарифнең модернизациясе, өзлексез мәгарифнең актуаль мәсьәләләре, мәгарифтә мәгълүматикоммуникатив технологияләр өлкәсендәге глобаль тенденцияләр һ.б. темалар турында да фикер алышу булды.

КФУның Психология һәм мәгариф институты вәкиле Г.Җ.Фәхретдинова «Казан (Идел буе) федераль университетында педагоглар әзерләү» темасы белән чыгыш ясады. Уку йортыбыздагы педагогик мәгариф моделе күпләрдә кызыксыну уятты. КФУ укытучылары шулай ук түгәрәк өстәлләрнең модераторлары буларак та катнашты. Е.М.Шувалова дискуссия кысаларында КФУда белем ала торган булачак педагогларда гражданлык бердәйлеге формалаштыру тәҗрибәсе белән уртаклашты.

Конференция эшчәнлеге барышында КФУ укытучылары чарада катнашучыларның стендлы докладлары, «Назарбаев Интеллектуаль мәктәпләре» Иҗтимагый берләшмәләр ассоциациясендәге инновацион технологияләр белән дә таныша алды.

• Очрашу

# Интеллигентлы журналист-тикшерүче

**Диләрә БАТРШИНА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты



«Журналист тикшерүе» жанрында иҗат итүче журналистлар күп. Аларның эше нидән гыйбарәт? Журналист-тикшерүче четерекле бер проблемага алынып (еш кына ул проблема җәмгыятьтән сер буларак саклана), ике каршы якның да фикерен тыңлап, объектив нәтиҗә чыгара. Эш катлаулы, һәр адым уйлап эшләнергә тиеш. Еш кына мондый жанрда иҗат итүче журналистларны каты характерлы, башкаларның хисләрен санга сукмаучы һәм һәрвакыт тәнкыйть, мөнәсәбәтләрне аңлату булган җирдә кайнаучы дип кузаллый идем. Дөреслектә, аларның исеме һәрчак кычкырыш-талаш белән бер яссылыкта куела бит, репутацияләре дә шул җәһәттән туа. Ләкин мондый кузаллавымны бер журналист тамырдан үзгәртте. Журналист-тикшерүчеләр арасында үз исеме өчен түгел, ә халык мәнфәгатьләре өчен эшләүчеләр дә бар икән!

Рәсимә апа Муллаян кызының «Журналист тикшерүе» курсында әлеге жанрда иҗат итүчеләр белән танышуны дәвам итеп, без, 4нче курс студентлары, очрашуга Илфат абый Фәйзрахмановны чакырдык. Чын мәгънәсендә интеллигент: очрашуның башыннан ахырына кадәр аягүрә (!) әңгәмә алып барды, бер такыр да телефон шалтыравына буленмәде, аның аша үз профессиональ эшләрен студентлар алдында кычкырып, масаеп хәл итмәде. Илфат абый күпкырлы шәхес: ул элек телевизион тапшырулар алып баручысы («Атна», «Әйбәт-гайбәт», «Ислах»), мөхәррир (2003нче елдан «Безнең гәҗит» исемле шәхси газета чыгаручы), журналист, үз редакциясе юристы һәм кайгыртучан гаилә башлыгы. «Алма пеш, авызга төш» дип түгел, ә һәр өлкәдә «Мин үзем эшлим!» дип торучы ул. Үзенең уңышлары, нәтиҗәле эшләре, һәркайда аны танулары, аңа игътибар итүләре белән бүлешсә дә, журналист-тикшерүче буларак үзеннән шурләп торуларын хәбәр итсә дә, Илфат абыйның сөйләмендә «минминлек» бөтенләй тоелмады. Әлә бу аның яхшы актерлык осталыгы, әллә дөрестән дә чын күңелдән безнең белән бүлешүе?!

Илфат абый Фәйзрахмановка мин, чын мәгънәсендә, сокланып утырдым. Татар телендә саф сөйләшүе, чын дикторларныкы кебек куелган дөрес тавышы, һәр сүзен үлчәп һәм уйлап кына әйтүе, объектив фикерләве – барысы да игътибарны җәлеп итте. Әлбәттә, аңа журналист-тикшерүче буларак янаучылар, аяк чалучылар бар. Бу, бигрәк тә, телевидениедә эшләгән чагында еш булган. Ләкин һәр журналистка да «үзе гаепле» дип әйткән кебек, Илфат абыйга андый мөһер куярга тел бармый. Чөнки аның һәр эше җәмгыять өчен файдалы фактлар һәм гаделлек белән тулы.

Әммә Илфат абыйга гадел булмаган бер закон яный. Килчәктә үз белеме буенча эшләмәгәннәрне хезмәт урыныннан алырга мөмкиннәр. Бу закон кабул ителсә, Илфат абый журналист һөнәреннән китәргә мәҗбүр булачак. Гаҗәп, бүгенге көнгәчә шушы өлкәдә кайнаган, татар телевидениесенә «тәнкыйть» дигән төшенчәне кертә алган шәхес мондый мөнәсәбәткә лекмы?!

•Ерактагы якын кардәшләр

# Татар теле дөньяга таныта

Алинә САДЫЙКОВА

2014-2015 нче уку елыннан Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г.Тукай ис. татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегендә Төркиянең Эгей университеты белән берлектә тәүге мәртәбә уртак магистратура программасы гамәлгә кертелде. Ике университет арасындагы әлеге килешү яңа үрләр яуларга менә дигән мөмкинлекләр тудыра.

### Максатларыбыз бер

Башкалабызга «Туган телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү» Халыкара форумында катнашу максаты белән килгән Эгей университеты профессоры, филология фәннәре докторы, тюрколог, телче Мостафа Өнәр үзенең тәҗрибәсе белән дә уртаклашты, Казан шәкертләрен яңа белемнәр белән баетты.

Мостафа әфәнде аеруча кыпчак телләрен яратып өйрәнә. Аның чагыштырма грамматика, сүзлекләр өлкәсендә хезмәтләре искиткеч күп. Ул, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты галимнәре белән һәрдаим элемтәдә торып, хезмәттәшлек алып бара.

Мостафа Өнәрнең дәресләре төрки телләрнең тарихы һәм чагыштырма нигезле грамматиканы өйрәнүгә йөз тоткан иде. «Безнең Төркиядә текстология фәнен өйрәнү бик популярлашты, аның буенча җыелган күп кенә материалларыбыз, хезмәтләребез бар. КФУ укучыларын да әлеге хезмәтләр белән таныштырам. Күренеп тора: аларга бу бик тә кызыклы. Дәресләремдә шуңа да игътибар итәргә тырышам: СССР чорында Казан, Баку, Алма-Ата кебек төбәкләрдә үз телләрен өйрәнү мөмкинлеге ачылды. Шуңа да һәр төрки республикада үз халкының мәдәнияте белән генә мавыгып, шуның белән эш итәләр иде. Ә Европа һәм Төркиядә тюркологияне өйрәнү бөтен төрки халыкларның мәдәниятләренчагыштырып алып барылды. Мәсәлән, минем бер укучым казах телен өйрәнсә, икенче бер укучым чуваш телен үзләштерә. Алар бөтенләй башка әйберләрне чагыштырып өйрәнәләр. Ә Азәрбайҗан, Казахстан, Татарстанда күбрәк үз темаларында тирәнәеп бардылар. Совет тюркологиясендә чагыштырма һәм тарихи анализ ясау булмады диярлек», – дип әйтә Төркия галиме.

Мостафа Өнәр бүгенге төрки телле өлкәләргә үзе барып, бу илләрнең тюркологиясен танытырга һәм булган тәҗрибәсе белән уртаклашырга тырыша. Аның фикеренчә, 210 еллык КФУны Европа стилендәге тюркологиянең үрнәге дип әйтеп була. Димәк, университетыбызда ул тәҗрибә бар. Шуңа күрә, республикада булдырылган мөмкинлекләрдән файдаланып, уку йортыбыздагы бик бай традицияле тюркологияне тагын да үстерергә, горизонтларын киңәйтергә тырышу – зарури әйбер

### «Татар телен өйрәтәм һәм өйрәтәчәкмен!»

Мостафа әфәнде татарча бик җиңел һәм иркен аралаша. Баксаң, ул студент чагында ук телебезне өйрәнеп, инде 25 ел дәвамында аны башкаларга да өйрәтә икән. Бу уңайдан ул: «Татар теле бөтен төрки дөньяга чыгу һәм лингвистик яктан башка төрки телләрне өйрәнү


▲ М.Өнәр КФУ студентларына дәрес бирә


М.Өнәр Эгей университеты әдәбият факультетындагы хезмәттәшләре белән ►

мөмкинлекләре бирә. Төрек теле угыз төркемендә булгач, безгә азәрбайҗан, төрекмән, үзбәк телләре якынрак. Кызганыч, төрки дөньяның төньягындагы телләр бездән ерактарак кала. Татар теле аркылы казах, кыргыз телләренә чыгу мөмкинлекләре табыла. Мин, шуңа күрә, бик яшь чагымнан татар телен өйрәнә башладым», – диде.

Мостафа Өнәр башта Г.Тукайның шигырьләрен өйрәнгән, аннан соң бик бай татар әдәбиятын үзләштергән. Аның фикеренчә, әсәрләрне укып чыгу, алар белән танышу – бик аз әйбер. Аларны бөтен төрки дөньяга танытырга да кирәк. Шуңа күрә, белгечлеге буенча булмаса да, Мостафа әфәнде күп кенә татар язучыларының әсәрләрен төрек теленә тәрҗемә иткән. Аларны Төркиядә бастырган һәм, шул рәвешле, татар әдәбиятын төрки аренага чыгаруда бәяләп бетергесез өлеш керткән. Гомумән әйткәндә, татар теле Мостафа әфәндегә үзенә бер төрле мәдәният дөньясын ачкан. Шуңа да, галим бу эшчәнлеген бүгенге көндә дә актив дәвам итә. Алай гына да түгел, бүгенге көндә профессор үз университетында 25 ел дәвамында татар телен башкаларга да өйрәтә. «Үзләре сайлаган, ирекле дәресләрдә без 15 кешелек төркемнәрдә татар булмаган студентларны укытабыз. Инде йөзләп укучы татар телен үзләштерде. Аларның кайберләре төрле университетларда укытучы булдылар. Араларында доцент, профессор дәрәҗәсенә ирешкәннәре дә бар. Укыту процессында, әлбәттә, кыенлыкларга да юлыгабыз. Шундыйларның берсе – әлифба, кириллицаны үзләштерү. Чөнки дәресләребездә борынгы татар әлифбаларын да, яңалиф, гарәп графикасын да өйрәнәбез. Мин, кулымнан килгәнчә, татар телен өйрәтәм һәм өйрәтәчәкмен дә», – Төркия галименең татар теленә карата шундый тойгылары сокланудан кала башка хис уятмый

### Тел белгән ил ачар

Төркиядә төрле җирләрдән күчеп урнашкан татар халкы вәкилләре байтак, ләкин киң җәмәгатьчелек конкрет рәвештә татар теле, татар дөньясы турында азрак белә икән. Бу уңайдан актив рәвештә пропаганда эше алып барыла. Мисал өчен, соңгы елларда Төркия университетларында, тюркология кафедраларыннан тыш, аерым төрки телләр кафедралары оеша башлаган. Алар эчендә махсус татар телен өйрәтү программалары да ачылган.

Мостафа Өнәр Казанда үзлегеннән төрек телен өйрәнгән татар яшьләре белән дә танышкан. «Төрек телен өйрәнгән кешегә бик күп мөмкинлекләр ачыла, чөнки Төркиядә бик күп китаплар чыга. Мисал өчен, бездә 2012-2013нче елларда 42 мең китап чыкты. Бу сан арта бара. Без, бик укыган халык кебек күренмәсәк тә, халык саны 76 миллионны тәшкил иткән илдә яшь буын китапка тартыла. Шуңа күрә, төрек телен өйрәнсәң, бөтенләй үзгә дөнья ачыла. Бу уңайдан КФУда төрек телен өйрәтү, Төркиядә исә татар телен өйрәтү программаларын арттыру турында да фикер алышу һәм сөйләшү булды», – дип, чит телләр өйрәнергә өндәде галим.

• Хатирә



# Даһи режиссер

«Ул театрны иҗтиһат кылды, ә театр халыкка хезмәт итә», дигән мәгънәле сүзләр белән башланып китте Милли музейда СССРның халык артисты, Рәсәй театр эшлеклеләре берлеге премиясе лауреаты Марсель Сәлимҗановның тууына 80 ел тулуга багышланган әдәби кичә.

Адилә ГЫЙЛАЕВА, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Марсель Сәлимҗанов 1966 елда, Г.Камал исемендәге театрның баш режиссёры буларак, үзенә һәм коллективы алдына үз тамашачыларын табу бурычын куя. 1969 елда Марсель Сәлимҗанов татар халкының милли байлыгы булган К.Тинчурин пьесаларын театр сәхнәсенә алып чыга. Танылган драматург әсәрләре буенча куелган бик күп спектакльләр режиссёр эшчәнлегендә күренекле урын алып тора, аларның һәрберсе образларның яңача ачылышы, сәнгати эшләнеше белән аерылып тора.

Халык мәхәббәтен яулаган спектакльләренең кайберләре: К.Тинчурин «Американ», «Сүнгән йолдызлар», «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл», К.Гольдони «Ике хуҗаның хезмәтчесе», А.Островский «Җимерелгән бәхет», «Бирнәсез кыз», Т.Миңнуллин «Әлдермештән Әлмәндәр», «Моңлы бер җыр», А.Гыйләҗев «Өч аршын җир», Ю.Сафиуллин «Идегәй», З.Хәким «Күрәзәче» һ.б. Халык шагыйре Разил Вәлиев: «Марсель Сәлимҗанов – татар театрының катык әчеткече иде ул. Катыкка әчеткеч никадәр кирәк булса, театрга да әлеге шәхес шуның кадәр кирәк кеше иде, – диде режиссер турында.

Марсель Сәлимҗанов, һичшиксез, милли театр сәнгатенең әйдаманы. Ул сәхнә телен, аның яшәү кануннарын, театраль зәвыкны яхшы белеп эш иткән.

Кичәдә режиссерны искә алып, Татарстан Республикасының халык артисты Илдар Хәйруллин болай диде: «Марсель аганы зур кеше дип әйтергә кирәк. Ул – гәүдәсе белән генә түгел, эшләре, планнары белән зур кеше иде һәм зур кеше булып безнең күңелләрдә калды да инде».

Аңа дәверне дөрес тоемлау, сәхнәгә кую өчен спектакльләрнең иң кирәклесен сайлый белү сәләте хас. Татар мәдәнияте һәм тарихын яхшы белү белән беррәттән, Марсель Сәлимҗанов дөньяда сәхнә сәнгате үсешенең перспективаларын да яхшы белгән.

Театрның үз тамашачысын булдыру, һичшиксез, режиссёрның олы хезмәте нәтиҗәсе. Һичнинди арттырусыз, Г.Камал театрының соңгы өч дистә елын М.Сәлимҗанов эпохасы дип атарга мөмкин.

• Дуслык дәресе

Институтыбызның Телевидение һәм тележурналистика кафедрасы укытучысы Шәкүрова Альбина Рим кызы студентлар белемнәрне тирәнрәк үзләштерсен, җиңелрәк кабул итсен өчен, дәресләрен кызыклы чаралар белән баетырга тырыша.

# Кызыклы очрашу

Кадрия ХӘСӘНОВА, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Алган белемнәрне гамәлдә куллану – шуларның иң мөһим өлеше. Мондый файдалы чараларның чираттагысын ул зачет сессиясе башланыр алдыннан махсус уйлап тапкан. «Визуаль багланышлар этикасы» («Этика визуальных коммуникаций») дип аталган курс кысаларында бакалавриатның икенче курс студентлары магистратурада укучы беренче курс студентлары белән очрашты. Үзенә күрә «зачет» тапшыру булды бу. Үзләреннән зуррак булган, инде билгеле бер белгечлек буенча һөнәр үзләштергән магистрантлардан студентлардан сораулар яуды гына. Фән кысаларыннан тыш та сөйләшү булды. Әлеге зачет-очрашу танышу, аралашудан бигрәк, тәҗрибә уртаклашуга юнәлтелгән иде. Ә монысы студент өчен, бигрәк тә булачак журналистларга, аеруча да мөһим. Магистрантлар үзләренең эш урыннары белән таныштырып кына калмыйча, студентларны практика узарга да чакырдылар. Кызыксынучылар күп булды. Шулай ук магистрантлар магистратурага укырга керүнең кирәкле һәм мөһим өлешләренә тукталып, студентларга киңәшләрен дә бирделәр.

● Мәнбәр

# Россиянең иң гүзәл ТАТАР кызы!

**Гүзәлия ГЫЙНИЯТУЛЛИНА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Без иң гүзәл татар кызы Алинә турында язып чыккан идек инде. Бар җирдә дә өлгер, уңган-булган туташ белән, зур җиңүләреннән соң дә очрашып аралаштык.

**– Алинә, сине чын күңелдән бу конкурста җиңүең белән котлыйм. Һәм «Татар кызы-2014» конкурсы турындагы тәэсирләрең белән уртаклашсаң иде.**

– Конкурста илебезнең төрле төбәкләреннән җыел-ган 20 кыз катнашты. Алар барысы да җиңү яулардай көчлеләр, чөнки үз төбәкләрендә кастингны үткән иделәр. Без, татар телен яхшы белүдән тыш, сәнгатьле итеп шигырь сөйләргә, җырлап-биергә тиеш булдык. Аш-суга осталыгыбыз да тикшерелде: токмачлы аш пешердек! «Татар кызы-2014» исеменә лаек булуыма чиксез шатмын. Конкурс барган ике атна эчендә осталык дәресләре дә үтте, Мәскәүнең күркәм җирләренә экскурсияләр һәм башка чаралар да уздырылды. Казанда үтәчәк йөзү спорты буенча 2015 ел чемпионатында мин илче булачакмын. НИК эксклюзив сәгате, дизайн күлмәкләре, алтын алкайөзек һәм башка бүләкләр иясе мин! Бу җиңүем белән мин барлык туганнарыма, якыннарыма, дусларыма рәхмәтлемен. Бу – безнең бердәм җиңү!

**– Бу бит синең беренче җиңүең түгел? Соңгысы да булмасын! Гомумән, кайчан үзеңдә көч, ышаныч тойдың?**

– Башлангыч сыйныфларда укыганда ук сәхнәдә чыгыш ясый башладым. Беренче укытучым Мөршидә Тимерхан кызы Ихсанова тамашачы алдында үзеңне тоту буенча беренче остазым булды. Әти-әниемнең ышанычы да миңа канатлар өстәде. Мәктәп һәм авыл чараларында катнаштым, оештыручы, алып баручы да булдым. Мәктәп КВН командасы капитаны да идем. Хәзерге җиңүләремнең асылында мәктәп елларында тәрбияләнгән сыйфатлар ята. Бүгенге көндә республика буенча чаралар уздырам, волонтерлар командасының кураторы булып торам.

**– Балачакта кем булырга теләдең? Хыялларың нинди, максатларың кайсы юнәлештә иде?**

– Кечкенә чагымда мин бары тик юрист булырга дигән катгый фикергә килгән идем. Кешеләргә ярдәм итү, хакыйкатьне исбатлау иде төп максатым. Хәзер исә инженер-эколог һөнәрен үзләштерәм. Һич тә сайлаган эшемнән тайпылырга уйламыйм. Башкаларга ярдәм итү өчен, юрист булу гына шарт түгел.

**– Чын татар кызы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?**

– Чын татар кызы, минемчә, үз татар халкының гореф-гадәтләренә тугры калып, татар телен һәм, аның барлык традицияләреннән тайпылмыйча, тарихын, мәдәниятен буыннан-буынга таратучы шәхес. Әлбәттә, боларга кушылып, татар кызының эчке һәм тышкы ягы да бертигез гармониядә яшәргә тиеш.

**– Алинә, син нинди татар ризыкларын пешерә беләсең?**

– Мин, аеруча, үзебезнең әби-бабайлардан килгән милли ризыкларны яратып пешерәм. Иң ятраткannары арасында дәү әнием белән бергәләшеп пешерә торган бәлеш, өчпочмак һәм, әлбәттә, Башкортстаныбызның милли ашамлыгы – баллы чәкчәк. Минем әнием – һөнәре буенча пешекче. Балачактан ук сеңлем белән безгә тәмле ризыклар пешерергә өйрәтте.

**– Бу конкурста үзеңә нинди тәҗрибә алдың?**

– Конкурс дәвамында безгә төрле билгеле кешеләр мастер-класслар, дәресләр үткәрде. Иң истә калганы Роза ханым Сябитова булды. Ул безне хатын-кызның җәмгыятьтә, гаиләдәге роле, аның хокуклары белән таныштырып үтте. Конкурс миңа бик күп шатлыклы минутлар, истәлекле эмоцияләр, яңа танышлар бүләк итте.

**– Синең өчен бу тормышта иң мөһим әйбер нәрсә?**

– Тормышта минем өчен иң мөһиме ул – гаилә. Нинди генә борчулар башымны biләмәсен, туып-үскән йортыма кайткач, барысы да онытыла. Өйдә мине көтәләр, анда мин рәхәтләнеп ял итәм, көч җыям.



**Безнең белешмә:**

*Тулы исеме:* **Гыйззәтуллина Алинә Чулпан кызы;**
*Туган көне:* **4 июнь;**
*Туган җире:* **Башкортстанның Туймазы районы Кандры авылы;**
*Гаилә хәле:* **кияүдә түгел;**
*Яраткан ризыгы:* **әнисе пешергән бәлеш;**
*Тормыш девизы:* **һәр туган көн – ул бәхет!**

● Дөнья үзебезнеке

# Чыңгызхан һәм аның лачыны хакында

*Пауло Коэльоның «Подобно реке» әсәреннән өзек*

**Гүзәл ФАРСЫЕВА,** Филология
һәм мәдәниятара багланышлар институты

Бервакыт иртән монгол илбасары Чыңгызхан үзенең яраннары белән ауга кузгалган. Аның юлдашлары ук һәм җәя белән коралланcалар, ул үзе белән яраткан лачынын алган. Әлеге кошның үткенлеге белән һичбер аучы да тиңләшә алмаган, чөнки ул үз корбанын кеше буе җитмәслек биеклектән – күк гөмбәзеннән күзәтергә сәләтле булган. Әмма һәвәскәр аучыларның ничек кенә мавыгуларына карамастан, араларыннан берсе дә һичнинди табыш, файда китерә алмаган. Аудан тәмам күңеле кайткан Чыңгызхан үз лагерена буш кул белән әйләнеп кайта һәм, начар кәефен сәбәп итеп, башка иптәшләреннән үч алмас өчен, яраннарыннан аерылып, берүзе бер тарафка китә.

Урманда озак тоткарланганлыктан, Чыңгызхан талчыга, сусый, тәмам хәлдән тая. Ел коры килгәнлектән, бик күп елгалар кипкән, бер тамчы су табу гаять авырлашкан була. Кинәт – могҗиза! Илбасар кыядан әзәзләп кенә саркыган чишмәне күреп ала.

Чыңгызхан һәрвакыт үзе белән йөрткән көмеш кәсәсен агым астына куеп, аның мөлдерәмә тулганын түземсезлек белән көтә башлый. Ниһаять, сусавын инде басам гына дигәндә, лачыны зур канатлары белән касәне хуҗасының кулыннан бар көченә бәреп төшерә.

Чыңгызхан ачуыннан шартлар дәрәҗәгә җитә, ләкин лачынын бик ятратканга, аның бу кыланмышын сусавыннан күрә. Ул, тузанланган касәсен җирдән күтәреп, яхшылап сөртә дә, янәдән агым астына куя. Ләкин савытның яртысы да тулырга өлгерми, лачыны янәдән аны хуҗасының кулыннан бар көченә бәреп төшерә.

Чыңгызхан, әлеге кошны җаныннан артык күреп яратуына карамастан, үзен шул рәвешле санга сукмауга, әлбәттә, юл куя алмый. Әлеге күренешкә шаһитлар табылып, башка гаскәрләре каршында ниндидер бер кошны да акылга утыртырга көче җитмәгән юлбашчы булудан гарьләнә ул.

Илбасар кылычын кыныннан тартып чыгарып, касәне янәдән агым астына куя һәм әле савытны, әле лачынны игътибар белән күзәтә башлый. Сусавын басарлык су җыелды дигәндә генә, лачын кабат кәсәне хуҗасы кулыннан бәреп төшерә. Бу юлы тәмам ярсыган хан кылычы белән кошның күкрәгенә кизәнә. Шул арада әкрен генә саркыган су тамчылары кимегәннән-кими һәм тәмам юкка чыга. Чыңгызхан чишмәнең үзен табарга тәвәккәлләп, кыяга үрмәли башлый. Ул чишмәнең нәкъ уртасында тирә-юньдә иң куркыныч саналган агулы еланнарның берсе булган үле хәшәрәтне күреп таң кала. Әлеге судан авыз иткән булса, үзенең күптән якты дөнья белән хушлашасын аңлап, бер мизгелгә ташталай басып тора.

Чыңгызхан лагерена үле лачынын үз кулларында күтәреп кайту гына түгел, ә яраткан кошының сынын саф алтыннан һәйкәл итеп итеп торгызырга һәм ике канатына түбәндәге гыйбарәләрне гыйбрәт итеп уерга боера:

«Дустың күңеленә ятышлы булмаган гамәлләр кылса да, ул барыбер синең дустың булып кала».

«Ачу белән кылган гамәл яхшылыкка алып бармый».

● Сәламәтлек

Авырый башлагач, саулыктан да зур байлык, аннан да кадерлерәк нәрсә булмавын аңлыйсың. Сәламәтлек саклауны яки нығытуны табиблар эше, дип кенә карарга ярамый. Һәркемнең саулыгы эшкә сәләтлеге үз кулында.

# Иммунитетың ныкмы?



Сәламәтлекне һәрдаим саклый белергә кирәк. Әйтик, иртәнге гимнастика тәнне чыныктыра, авырудан тизрәк котылырга ярдәм итә. Ә спорт төрләре гаҗәеп күп. Бары тик үзеңә кирәклесен сайлап ала белергә, ихтыяр көче булдырып даими шөгыльләнергә генә кирәк.

Авыру-авырмау организмның иммун системасына да бәйле. Иммунитетың нык икән, димәк, син төрле чирләрдән азат дигән сүз. Йокысызлыктан интегүчеләргә һәм организмны ныгыту өчен түбәндәге катнашма файдалы.

Ул болай ясала: 1 стаканга 1 аш кашыгы алоэ согы, 1 аш кашыгы бал, 1 аш кашыгы табигый сок (кәбестә, алма, әфлисун…) саласың. Аннары стакан тулганчы кайнар су агызырга, болгатырга һәм караңгы салкынча урынга куярга кирәк. 10 сәгатьтән катнашма әзер була. Аны өлкәннәргә бер ай буе, көнгә бер аш кашыгы, балаларга 10-12 көн дәвамында 1 чәй кашыгы эчәргә киңәш ителә. Аннары 2-3 атна ял итәргә һәм тагын әзерләп, 2 цикл эчәргә кирәк.

Катнашма шулай ук аяк туңуны бетерә, организмның төрле чирләргә каршы торучанлыгын арттыра.

DARELFONYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.